**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 июнендәге 1716 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Вахитов районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2, 3, 4 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- ЗУ 1 йогынты ясый торган өлкә мәйданы – 9 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:011131:1193;
- ЗУ 2 йогынты ясый торган өлкә мәйданы – 80 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:011131:1193;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы;
- билгеләү максаты: электр белән тәэмин итүне (технологик тоташтыруны) оештыру өчен;
- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округы Генераль планы, 2022 елның 1 июнендәге 2022500/52/03596 номерлы гариза буенча электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында 2022/КЭС/Т575 номерлы шартнамә.

2. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2, 3 һәм 4 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарның 2 һәм 4 номерлы кушымталарыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегенең хокук иясе белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;

7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аңардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә;


7.3. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрен һәм сак предметын раслау турында»гы боерыгы нигезендә чикләүләрне үтәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1716 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

# Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре





| | |
|---|---|
| Масштаб 1:250<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Сервитутлар (статуссыз) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:011131 | кадастр кварталы |
| 16:50:011131:1193 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1716 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




| | |
|---|---|
| Масштаб 1:500<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| ▭ | Сервитутлар (статуссыз) |
| 16:50:011131 | кадастр кварталы |
| 16:50:011131:1193 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |